**Класс:** 4
**Укытучы:** Касыймова Зөһрә Илсур кызы
**Программа:** Перспектива
**Тема:** Безнең елгалар
**Максаты**: Укучыларда Россиянең елгалары турында күзаллау булдыру

**Дәрес барашы:**

**-Хәерле көн, укучылар! Сезнең белән кабаттан күрешүемә мин бик шатмын. Дәресебезне башлыйбыз.**

**- Укучылар, бу нәрсә?** (Глобус). **Дөрес, бу безнең планетабыз – Җирнең макеты.**

**-Анда зәңгәр төс белән нәрсәләр сурәтләнә?** (Сулыклар)

**- Нинди сулыклар бар икәнен искә төшерик әле. Сез аларны әйтә аласызмы?** (Елга, диңгез, океаннар, күлләр)

**<u>Слайд 2</u>**

**- Без бүген илебезнең су киңлекләре буйлап сәяхәткә кузгалырбыз . Ә кайсы тукталыштан башлаганыбызны белер өчен, сезгә әлеге тамышмакның җавабын табарга кирәк.**

**<u>Слайд 3</u>**

* Башы тауда, аягы диңгездә. (Елга)

**Бу танышуны без елгалардан башлыйк. Чөнки елгалар һәрвакыт кешеләр тормышында аерым әһәмияткә ия булган.**

**<u>Слайд 4</u>**

Безнең ерак бабаларыбыз елга буйларына килеп урнашканнар: башта авыллар төзегеннәр, аннары аларның күбесе зур шәһәрләргә әйләнгән. Елгалар илнең төрле почмакларын тоташтырып торучы су юллары булган. Алар үзләренең матурлыклары белән кешеләрне сокландырган, аларда якты хисләр уяткан. Кешеләр су агымына карап, үткән гомер һәм киләчәк турында, вакыт агышларында үзләренең урыны хакында уйлаганнар. Хәзер дә бу дәвам итә.

**<u>Слайд 5</u>**

**Елгалар - күлләр кебек үк, Россиянең байлыгы һәм горурлыгы. Елгалар табигый агып тора торган сулар. Алар җир өсте һәм җир асты сулары белән туенып торалар.**

**Елгалар төрле була: кечкенә һәм зур елгалар, тигезлек һәм тау елгалары, сай һәм тирән елгалар... Аларның уртаклыгы нәрсәдә сон?**

**<u>Слайд 6</u>**

Теләсе нинди елганың **башы** һәм **тамагы** бар. “Башы” дип- елганың башланган урынын, ә “тамагы” дип аның икенче елгага, күлгә яки диңгезгә койган урыны атала. Елганың ике яры- уң һәм сул **ярлары** була. Агым уңаена карап бассаң, уң якта- уң яр, ә сул якта- сул яр була. Елгага, гадәттә, башка елгалар килеп кушыла. Алар **кушылдыклар** дип атала.

**<u>Слайд 7</u>**

Безнең илдә озынлыгы 10 км арткан 120 меңгә якын елга исәпләнә. Ә иң кечкенә елгаларны да кертеп исәпләсәк, елгалар 2 миллионнан да артып китә! Һәм алар барысы да- Россиянең байлыгы һәм бизәге.

**Илебезнең күплəгəн елгаларыннан унысын сайлап, алар белән якынрак танышыйк.**

**<u>Слайд 8</u>**

**Идел** (Волга)- Россиянең Европа өлешендә һәм бөтен Европада иң зур елга. Аның исеме һәрбер Россия кешесенең йөрәк түрендә. Элек-электән аны, хөрмәтләп һәм яратып “Идел- анакай” дип йөрткәннәр. Идел ярлары буйлап берсеннән- берсе матуррак искиткеч шәһәрләр: Тверь, Ярославль, Кострома, Түбән Новгород, Чабаксар, Казан, Ульяновск, Самара, Саратов, Волгоград, Әстерхан бер сафка тезелеп урнашканнар! Иделгә 200 гә якын кушылдык коя. Аларның иң зурлары: **Кама (Чулман) һәм Ока....**

**Слайд 9**

Оканың данлыклы кушылдыгы- **Мәскәү** елгасы. Бу гүзәл елга буенда Туган илебезнең башкаласы Мәскәү шәһәре балкып утыра. Шәһәр эчендә елганың ярлары гранит белән ныгытылган, ә аның суында Мәскәү Кремле стеналары һәм манаралары чагыла.

**Слайд 10**

Россиянең Европа өлешенең төньяк- көнбатышында тагын бер данлыклы елга бар. Ул үзе озын түгел, ә даны бик зур. Бу- **Нева** елгасы, аның яр буена искиткеч шәһәр- Санкт- Петербург төзелгән. Шәһәрнең төп урамы, елга атамасы белән Нева проспекты дип йөртелә.

**Слайд 11**

**Россиянең Европа өлешенең көньягында Дон елгасы ага. Аның ярларында зур шәһәр- Ростов- Дон урнашкан**.

**Хәзер Россиянең Азия өлешенә юл тотыйк.**

**Слайд 12**

Себернең бөек елгалары- **Обь, Енисей, Лена-**россиялеләрнең даны һәм горурлыгы. Алар Төньяк Боз океанына коялар. Бу елга буйларында бик зур шәһәрләр - Новосибирск (Обь буенда ), Красноярск (Енисей буенда), Якутск (Лена елгасы буенда) төзелгән.

**Слайд 13**

Ерак көнчыгышның төп елгасы- **Амур.** Ул Тын океанга коя. Аның ярларында Хабаровск шәһәре. Амур - чик буе елгасы, аның буенча Россия белән Кытай чигенең бер өлеше үтә.

**-Дәресебезнең теория өлеше тәмам, практик өлештә күрешербез.**

**2нче (практик) өлеш**

**-Сезнең белән кабаттан күрешүемә мин бик шатмын. Хәзер Россиянең елгалары**

**турында туплаган мәгълүматны тикшереп карыйк. 1)Беренче бирем.**

**Слайд 14**

Өйрәнгәннәрдән чыгып һәм картаны кулланып, шәһәрләрнең кайсы елга буенда урнашуын ачыкла.

<table>
<tr><td>Идел</td><td rowspan="5">Хабаровск<br>Санкт- Петербург<br>Ростов- Дон<br>Казан<br>КолОмна<br>Пермь<br>Якутск<br>Новосибирск<br>Красноярск<br>Мәскәү</td><td>Дон</td></tr>
<tr><td>Кама (Чулман)</td><td>Обь</td></tr>
<tr><td>Ока</td><td>Енисей</td></tr>
<tr><td>Мәскәү</td><td>Лена</td></tr>
<tr><td>Нева</td><td>Амур</td></tr>
</table>

**Слайд 15**

**Җавапларыңны чагыштыр.**

<table>
<tr><td>Идел</td><td rowspan="5">Хабаровск<br>Санкт- Петербург<br>Ростов- Дон<br>Казан<br>КолОмна<br>Пермь<br>Якутск<br>Новосибирск<br>Красноярск<br>Мәскәү</td><td>Дон</td></tr>
<tr><td>Кама (Чулман)</td><td>Обь</td></tr>
<tr><td>Ока</td><td>Енисей</td></tr>
<tr><td>Мәскәү</td><td>Лена</td></tr>
<tr><td>Нева</td><td>Амур</td></tr>
</table>

**2)Киләсе биремгә күчәбез. Өйрәнгән мәгълүматны файдаланып, рәсемдә билгеләнгән елганың өлешләрен ата.**

**Слайд 16**

**Эшегезнең дөреслеген дәреслекнең 138нче битеннән тикшерегез.**

**3) Ә хәзер 3нче биремгә күчәбез. Сүз кайсы елга турында бара?**

**Слайд 17** Әлеге елга Идел елгасы белән чагыштырганда күпкә мул сулырак (полноводний) булуына карамастан, аның кушылдыгы булып санала. (Кама)

**Слайд 18** Байкал күленнән агып чыгучы бердән- бер елга. (Ангара)

**Слайд 19** Кайсы елгада хатын-кыз исеме яшерелгән? (Лена)

**Слайд 20** Ерак көнчыгыш картасында нинди мәхәббәт алиһәсе бар? (Амур)

**Слайд 21** Кайсы елгалар юл буйлап йөгерә? (Волга, Ока, Иж)

**Слайд 22** Россиядәге иң озын елга. (Лена 4400км)

**Слайд 23** Санкт- Петербург шәһәре аша үтүче елга. (Нева)

**Слайд 24** Россиядәге иң киң елга. (Обь 80км)

**Слайд 25** Әлеге елгага нинди генә исемнәр биреп карамаганнар: Ра, Арак, Итиль, Етемия, Ердиль. Сүз кайсы елга турында бара? (Идел)

**Слайд 26**

**4) Алга таба, укучылар, сезгә бүген без өйрәнгән елгаларны контурлы картада билгеләргә кирәк булачак.**

**4) Ә хәзер, укучылар, мин сезне карта буенча викторина үтәргә чакырам. Сезгә әлеге сылтама аша кереп, тиз арада бирелгән елганы картадан табарга кирәк.**
https://www.geoguessr.com/seterra/ru/vgp/3133 (экранда чыга)

**Бу безнең дәресебезнең соңгы биреме. Уңышлар телим сезгә! Киләсе очрашуларга кадәр!**